ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза, 422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагужа авылы, 422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                КАРАР

02.04.2024                с. Коргуза                02

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

«Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылында гражданнар җыенының 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылында гражданнар җыенының 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 апреленә гражданнар җыенын билгеләргә».

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 02 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (бистә эчендәге юлларга вак таш салу).

«ӘЙЕ»                «ЮК»

3. Карагуҗа авылы, Үзәк мәйдан, 3 йорт адресы буенча Карагуҗа авыл мәдәният йорты бинасы янында13.00 сәгатьтә халык җыенын уздырырга.
4. Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы                Д.В.Плохов